**9 – Т – 2016**

**Бикбатыр белән Биккуркак**

Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара бик тату яшәгәннәр. Куян, кетер-кетер итеп, агач кайрысы кимергән, ә песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән.

Песи бернәрсәдән дә курыкмый икән, аңа теге бала "Бикбатыр" дип исем кушкан. Куян, дер-дер килеп, бар әйбердән дә шүрли, аны ул "Биккуркак" дип атаган.

Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән. Куркуыннан Куян нишләргә дә белмәгән, баскан урыныннан кузгала да алмаган. Ярый әле Бикбатыр килеп җиткән һәм Биккуркакка бераз көч кергән: "Әй юләр, юләр, − дигән Бикбатыр, − үз шәүләңнән үзең куркып торасың ич", − дигән. Биккуркактан көлгән. "Ярый әле син килдең, Бикбатыр, куркуымнан үлгән булыр идем", − дигән Куян.

Икенче бервакытны Куян тагын куркуга төшкән, йөрәге аның дөп-дөп типкән, нәрсәдер бик нык итеп кыштырдый икән. "Хәзер идән астыннан чыга да, кыштырдаучы нәрсә мине кабып йота", − дип уйлый икән Куян.

Песи дә колакларын торгызган, ул да курка, ахры, дип уйлаган Куян. Шулчак нидер шап итеп дөбердәп киткән. Куян һушсыз була язган. Ә Песи, авызына нәрсәдер кабып, Куян янына килгән.

Килгән дә: "Менә сине куркытучы нәрсә шушы инде", − дигән, бер кечкенә генә кара әйберне Куянга күрсәткән. "Шушы кечкенә генә фетнә шулкадәр тавыш чыгара аламы?" − дип, Куян гаҗәпләнеп караган.

Өченче бер тапкыр ачык ишектән бер эт килеп кергән һәм каты итеп өрергә керешкән. Куян карават астына кереп качкан. Ә Бикбатыр идән уртасына чыгып баскан, зур күренергә тырышып, сыртын кабарткан, эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган. Билгеле, эт аңа кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган.

Ә Бикбатыр үзенең батырлыгы аркасында бу бәладән дә бик оста котылган.

(А. Алиш)

1. Әсәр нинди жанрда иҗат ителгән?

2. Аның идеясе нинди?

3. Әсәрдә нинди образлар бар? Биккуркакның һәм Бикбатырның сыйфатларын билгеләгез.

4. *Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара бик тату яшәгәннәр. Куян, кетер-кетер итеп, агач кайрысы кимергән, ә песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән.* Бу әсәрнең нинди сюжет элементы?

5. *Коточкыч* сүзен транскрипцияләгез.

6. Бикбатыр белән Биккуркак үзара нинди сүзләр?

7. *Чыгып сызган* тезмәсенең синонимнарын табыгыз.

8. Ясалышы ягыннан *һөҗүм итсә* фигыле нинди төргә карый?

9. *Кыштырдаучы* сүзенә морфологик анализ ясагыз.

10. *Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән.* Җөмләнең схемасын төзегез.

**10 – Т − 2016**

**Бәхет**

Бер шәһәрнең читендә генә өч агай-эне торалар иде. Боларның, нинди генә эшкә тотынсалар да, ни сәбәптәндер эшләре уңга китми иде.

Бу агай-энеләр эшләре уңмавында үз-үзләрен гаепләргә уйлап та карамыйча, һаман Бәхет юклыгыннан гына күрәләр иде.

Берзаман ничектер Бәхет, күзгә күренмичә генә, боларга кунакка килде дә бу өч агай-энегә, нинди генә эш башласалар да, ярдәм итәргә сүз бирде.

Бу вакытта өч агай-эненең берсе сәүдәгәрлеккә тотынган иде. Дәрхаль Бәхетнең ярдәме илә ни сатса – аннан файда, ни алса – аннан табыш итеп, берничә көндә малы вә хәзинәсенең хисабы булмаган бер зур бай булып китте.

Шул ук Бәхет килгән заманда икенче кардәше мәхкәмәдә кятиб (писарь) иде. Бу да Бәхет аркасында хакимлек дәрәҗәсенә күтәрелде; медальләр бирелде.

Сез инде өченчесенә дә Бәхет ярдәм иттеме, диярсез.

Ник итмәсен, итте: өченче кардәш чебен тота иде. Хәзер, Бәхетнең булышлыгы илә, кулын селтәгән саен чебен тота; һичбер селтәгәне бушка китми.

Бәхет кунакка гына килде, дигән идек бит. Дөрес, Бәхет озакламады, китте.

Ике карендәш зур бай вә дәүләтле булдылар. Өченчесе, һаман явыз Бәхетне яманлап, авылдан авылга, сукрана-сукрана, капчык тотып теләнергә китте.

(Г. Тукай)

1. Әлеге әсәр нинди жанрда иҗат ителгән?
2. Әсәрнең темасын атагыз.
3. Әсәрнең төп идеясе нинди?
4. Әсәрдә нинди образлар бар?
5. *Ике карендәш зур бай вә дәүләтле булдылар.* Бу җөмләдә *бай* һәм *дәүләтле* дигән сүзләр үзара нинди сүзләр?
6. Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан *дәрхаль, мәхкәмә, кятиб* сүзләре нинди төркемгә карый?
7. *Өченчесе* сүзенә фонетик анализ ясагыз.
8. *Бәхет* сүзенә лексик анализ ясагыз.
9. *Карендәш* сүзен ясалыш ягыннан тикшерегез.
10. *Сукрана-сукрана* сүзенә морфологик анализ ясагыз.

**11 – Т – 2016**

## Сагыну

Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм, шунда тизрәк кайтып керер өчен, Берлинга ашыгам. Берлинга мин, илем белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен, чиксез ачу белән барам...

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төен тыгыла. Мин төенне йота-йота җавап язам:

Телеграмм баганасы – олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы дип сорыйсыз – сагынмаган кая ул!

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп мин ачык аңладым: кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

(Г. Кутуй)

1. Әсәр нинди жанрда язылган?
2. Әсәрнең темасын һәм идеясен ачыклагыз.
3. Әсәрдә нинди образлар бар?
4. Әсәрдән рефрен җөмләне табыгыз.
5. Әсәрдәге эпитетларны табыгыз.
6. *Чишмәләребезнең* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз.
7. *Болынлыктагы, сагынуым, борынгы* сүзләрен транскрипцияләгез.
8. Текстан гидронимнарны табыгыз.
9. *Кайтуым* сүзенә морфологик анализ ясагыз.
10. *Чит илдә йөреп мин ачык аңладым: кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.* Җөмләнең схемасын төзегез.